# Татарстан Республикасы
# Дәүләт Советы Президиумы

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структурасына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структурасын камилләштерү һәм штат санын оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратында Оештыру идарәсенең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек бүлеген, аның функцияләрен Оештыру идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советында фракцияләр эшчәнлеген тәэмин итү һәм оештыру эшләре бүлегенә тапшырып, бетерергә.

2. “Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структурасын үзгәртү һәм штат санын оптимальләштерү турында” 2010 елның 22 октябрендәге 1205-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарына 2 нче кушымтаны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре:

– Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр әзерләргә һәм аларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы раславына кертергә тиеш;

– Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структурасына әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының штат расписаниесенә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Административ регламентына үзгәрешләр әзерләргә һәм аларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе раславына кертергә тиеш.

4. Әлеге карар 2014 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2013 елның 17 декабре
№ 3233-IV ДС

C:\ДИСК C\ILSIA\PEREBOD\Sessia\2013\17 декабря-президиу

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2013 елның 17 декабрендәге
3233-IV ДС номерлы карарына
кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ СТРУКТУРАСЫ

